**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 август № 557

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче; 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән – физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә вазыйфаларын башкарганда (04.04 <*>);»;

4.1 нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә теркәлгән үзйөрешле техникага әледән-әле техник тикшерүләр үткәрү;»;

7.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары, структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков